СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИЖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

11 июль, 1997ел.
ҖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 75 (8087) | Бәясе билгеләнгәнчә




Андрей - Андреевкада туып үсте. Авыл баласының һәркайсы кебек үк ул да яшьли техникага гашыйк булгандыр, мөгаен. Нефтьче һөнәре турында да хыяллангандыр бәлки. Аларның Андреевка авылын көне - төне ял белмичә нефть суыртучы сиртмәле коелар урап алган бит. Зур - зур вахта машиналары белән аларның авылы аркылы кайтып - китеп йөрүче нефтьчеләрне танып белмәсә дә, күзаллый ул: болар бит җир куенынннан ургылып килүче нефтьне чыгаручылар, аны торбалар буйлап озатучылар.

Хәзер Андрей үзе дә шул ук нефтьчеләр белән иргә эшли. Өченче номерлы нефть һәм газ чыгару цехында (ЦДНГ) өлкән оператор ул. Бүгенге көндә төп хезмәт стажы өч елга якын гына булса да егет сынатмый: вазифасын тел - теш тидермәслек итеп башкара. Цех җитәкчелеге дә аның фамилиясен алдынгылар исемлегендә атый.

**Рәсемдә: 3 нче ЦДНГ өлкән операторы А.Колесников.**

**Н.КВАШНИНА фотосы.**

## «Уңыш - 97» матбугат үзәге хәбәр итә

**Район буенча 9 июльгә әзерләнгән коры печән 17 мең тоннадан артык иде. Муса Җәлил исемендәге хуҗалыкта бу төр азык планның 84, «Комбайн» һәм «Рассвет»та 77 - 78, «Родина», «Алга», «Әлмәт» һәм «Заветы Ильича»да 62 - 68 проценты кадәр туплап куелды, тагын берничә хуҗалыкта ярты планнан күбрәк. Шул ук вакытта коры печәнне планның өчтән бере кадәр дә тупламаган хуҗалыклар бар әле. Ярый әле аларның кайберләрендә хәл аларда сенажның чагыштырмача күбрәк булуы белән аклана. Анысын салуга хуҗалыкларның яртысыннан артыгында тотындылар инде һәм район буенча сусыл азыкның запасы 6 мең тонна чамасы хәзер.**

**Витаминлы үлән оны 300 тоннага якын ясалды. Мичурин исемендәге хуҗалыкта бу төр азык беръярым план күләмендә инде, «Кондырча», Синдряков исемендәге, «Заветы Ильича» хуҗалыкларында да шактый ук.**

**Витаминлы азыкларның икенче бер төре яфрак азыкның да быел мулдан туплануын билгеләп үтмичә булмый. Бу яктан нефтебазаның һәм «Агрохимсервис»ның ярдәмче хуҗалыкларында, «Родина», «Рассвет», «Якты Күл»дә маллар быел кыш яфрак азыкка кинәнер дип ышанырга кирәк - аларда бу төр план тулды яки шактый ук арттырып та үтәлде. Быел витаминлы һәм дару үләннәре җыю да башка еллардагыдан шактый уңышлы оештырылды.**

**Әмма болар гына тынычланырга ирек бирми әле. Сенаж салуга барлык хуҗалыкларда да тиз көннәрдә массовый тотынмаган тәкъдирдә бу эшнең бик кыенга каласы бәхәссез. Базларга урнаштырыла торган массаның сыйфатын да көндәлек тикшереп тору сорала.**

## ТАГЫН БЕР «ТУРГАЙ»

Шәһәр читендәге 19 нчы ягулык салу станциясе янына төзелеп куелган компактлы тамак ялгау урыны «Тургай» дип атала. Әле яңа гына эшли башлавына да карамастан, аны норлатлыларның байтагы белә инде. Биредә кыска вакыт эчендә тамак ялгап чыгарга яисә үзең белән юлга кабымлык ризык сатып алырга мөмкин. Иң мөһиме, «Тургай»га иртән 7ләрдә, кичке 11 ләрдә керсәң дә ачык була. «Норлатнефтепродукт» акционерлык җәмгыяте җитәкчелеге якын киләчәктә аны тәүлек буена эшләтүне максат итә.

## Игътибар! Игътибар!

*Шимбә көнне, 1997 елның 12 июлендә 10.00 сәгатьтә Норлатның үзәк стадионында «Уяв» чуваш фольклор бәйрәме үткәрелә.*

*Программада:*

*- Чуваш фольклор ансамбльләре чыгышы;*

*- спорт - күңел ачу программасы;*

*- кул эшләре күргәзмәсе;*

*- милли эчемлек - сыра белән сыйлау;*

Кичен 17.00 сәгатьтә район культура йортында игелек концерты.

Билет бәясе - 5 мең.

*Бәйрәмгә рәхим итегез!*

*Оештыру комитеты*

*Районыбыз тормышыннан хәбәрләр*

## МӘКТӘПЛӘР КӨЯЗЛӘНӘ

Мәктәпләрдә чагыштырмача тынлык бүген. Бары тик ремонтчылар гына бозалар бу тынлыкны: район белем бирү учреждениеләре яңа уку елына хәзерләнә. Кайберләренә капиталь ремонт үткәрелә, икенчеләренә агымдагысы гына. Шәһәрнең икенче, өченче номерлы, Фома урта мәктәпләрендә быел ягулык системасы тулысынча алыштырыла. Киекле, Чулпан, шәһәрнең беренче урта мәктәпләрендә түбә - түшәм төзәтелә. Стеналар, идәннәр, парталарны буяу, түшәмнәр агарту кебек эшләрне исә барлык мәктәпләр дә үткәрә. Укытучылар, укучылар, ата - аналар тартылган бу эшкә.

Әлегәчә район белем бирү учреждениеләренең берничәсе генә табигый газ белән җылытуга көйләнгән иде. Агымдагы уку елы дәвамында учреждениеләренең 15ләбе бу мөмкинлектән файдалана башлар дип көтелә. Шуңа да мәктәпләрдә, балалар бакчаларында моңа хәзерлек эшләре дә киң җәелдерелде: газ казаннары, башка төрле җиһазлар сатып алына, гомумән, һәръяклы хәстәрлек күрелә.

Билгеле инде, бүгенге шартларда ремонт үткәрү җиңел түгел. Хәзер бит аның буяулары, агач материаллары гына да күпме тора. Ә газ җиһазлары тагын... Барысына да акча кирәк. Ярый әле, район хакимияте мәгариф өлкәсенең ихтыяҗларын дөрес аңлап, безгә ярдәм итү мөмкинлекләрен таба тора. Бу безгә барлык мәктәпләрне дә август башында төзәтеп бетерергә реаль мөмкинлек тудыра. Укучыларның яңа уку елын төзек чиста, якты биналарда башлаячакларына өмет тә көннән - көн ныгый.

**Н.АБДУЛЛИН,
район мәгариф бүлеге мөдире.**

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

***Татарстан Республикасы Президенты Карары нигезендә, районыбызның Мичурин исемендәге кумәк кооператив рәисе Ильяс Нургали улы Мөхәммәтовка, «Алга» крестьян хуҗалыклары ассоциациясе рәисе Рәфис Рәфыйк улы Хәмзинга «Татарстан Республикасының атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исемнәр бирелде.***

## Дуңгызчылык игътибар сорый

Районда дуңгызчылык тармагын аякка бастыру буенча зур оештыру эше башкаруның нәтиҗәсе буларак, күпчелек хуҗалыкларда бу тармакта эшләр күзгә күренеп яхшырды һәм хәзер дә уңайга бара. Хуҗалыкларда ана дуңгызларның санын кискен арттырып, аларны турлап балалатуга әзерләү нәтиҗәсендә быел алты айда район буенча 22 мең ярым чамасы дуңгыз баласы алынып, бу узган елгыдан 171 процентка артыграк булды.

Дөрес, хәл бар урында да бертөсле түгел. Шуңа да «Заветы Ильича», Муса Җәлил исемендәге һәм «Рассвет хуҗалыклары базасында шушы тармакта эшләрнең торышын тикшерүгә һәм хәлне тагын да яхшырту, аерым алганда, җәйге лагерь шартларында алынган яшь үрчемне, балалаган һәм каплатуга әзерләнә торган аналарны ашату һәм карау, ел ахырына тагын бер тур үрчем алу өчен бүгеннән әзерлек башлау мәсьәләләренә багышлап куст семнарлары уздырылу урынлы иде. Хуҗалыкларның баш зоотехниклары һәм ветеринария врачлары, дуңгызчылык фермалары мөдирләре катнашында узган бу семинар - киңәшмәләрдә ачыктан - ачык һәм җитди сөйләшү булды. Авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсенең терлекчелек бүлеге башлыгы Ф.Г.Минһаҗев һәр хуҗалыкның дуңгызчылык тармагында яртыеллык эш нәтиҗәләренә, гомумән тармакта эшнең оештырылуына җентекле анализ ясады, дуңгызчылыкны аякка бастыру юнәлешендә шактый зур эш башкарылса да, кайбер урыннарда, шул исәптән элек бу өлкәдә гел алдынгы булган кайбер хуҗалыкларда да җитди кимчелекләр булуын күрсәтеп, хәлне уңай якка үзгәртү өчен кичекмәстән күрелергә тиешле чараларга тукталып үтте.

## ҺӘРКЕМ ӨЧЕН ҖАЙЛЫ

«Норлат машина төзү заводы» АҖсе каршында быел яз эшли башлаган салон - кибет үз сатып алучыларын тиз тапты. Заводта эшләүчеләр биредән кирәкле товарларны хезмәт хакы исәбенә ала алалар - бу алар өчен бик уңайлы. Норлатлылар исә биредән товарлар алу белән бергә, көнкүреш кирәк - яраклары - металл коймалар, тагараклар, базлар һәм башкаларга заявкалар да бирә алалар. Соңгысын заводта тиз арада эшләп бирәләр, хаклары кибеттә үк күрсәтелгән дә. Сатучы Наталья Никифоровадан да уңдылар заводлылар: ачык йөзле, киң холыклы Наталья эшен бик теләп башкара.

*Рәсми хәбәрләр*

## Яңа директор билгеләнде

«Надежда» дәүләт предприятиесе директоры Р.С.Хәмидуллин башка эшкә күчерелү сәбәпле, предприятие директоры итеп Е.В.Абрамов билгеләнде.

# Сынауда сынатмаслык

Район чигендә, агач массивына сыенып утырган Тимерлекнең җирләрен уңдырышлы дип булмый. Туфрагы комлы, көлсу. Урман аланнарында уйдык - уйдык булып урнашкан басу мәйданнарында техника белән эшләве дә катлаулы әле өстәвенә. Әмма араларында яннан килеп эшләүче бер кеше дә булмаган, кендекләре белән җиргә береккән механизаторлар өчен проблема тудырмый бу. Бер генә елны да читтән кеше китертеп эшләткәннәре юк кырларында. Югыйсә, комбайннарга нагрузка да аз төшми. Комбайннары да берничә дистә уракта сыналган: иң соңыннан алынган «Нива»га да 10 ел. Шулай да тырышалар. Әнә, узган ел уракны районда беренчеләрдән булып төгәлләделәр бит. Ә уңышы нинди булды тагын! Бөртекле һәм бөртекле - кузаклыларның һәр гектарыннан гомердә күрелмәгән уңыш - 24,5 центнер җыйдылар. Ызандаш - хуҗалык - МСОның ярдәмче хуҗалыгындагыдан ике тапкырга артыграк булды ул. Уңышның төп «үлчәвен» уҗым культуралары күтәрде. Ни дисәң дә, урман уртасындагы басуларда уҗымнар яхшы кышлый. Шуңа да хуҗалыкта уҗым культураларын мөмкин кадәр күбрәк чәчүгә йөз тоталар. Дөрес, тулаем районда да алар аз чәчелгән. Узган елда бөртек өчен 420 гектарда гына күмдерелде. Шулай да алар өметле күренә.

- Урыны - урыны белән һәр гектардан 40 центнерга якын чыгачак,- ди баш агроном В.Краснов.

Сабан культуралары да башак тутырып килә. Билгеле инде, хуҗалыкның район үзәгеннән ерак урнашуы сәбәпле, ашлама белән әллә ни өлгер эшләп җиткерә алмыйлар әле. Әмма башка төрле агрочараларның берсе дә үтәлми калмады.

Бүген хуҗалыкта уракка хәзерлек киң җәелдерелгән. Техника төзәтүгә игътибарның иң зурысы юнәлтелгән. Механизаторлар күн буе комбайннары янында әвәрә киләләр: шактый искергән «кыр корабларын» эшче хәлгә китерү өчен шактый тырышасы бар. Төзек булмаган узел - детальләр урынына яңаларын гына алып куясы да бит, акча ягы такыр. Ярый ла шәһәрдәге хуҗалары - РСУ һәрьяклап ярдәм итә әле. Шулай да механизаторлар яңага өмет итеп ятмыйча, иске узел - детальләрне үзләре үк реставрацияләү, яңарту белән дә шөгыльләнәләр. Әнә, Веналий Шмелев «Нива»сын беренчеләрдән булып эшче хәлгә китерде. Константин Герасимов «кыр корабын» кырда сынарга да өлгерде: донникны теземнәргә салды ул. Анатолий Восленниковның «Нива»сы да төзәтелеп бетте.

Берүк вакытта автомашиналарны карау - көйләүгә дә игътибар зур. Ындыр табагында да күптән инде җанлылык сизелә. КЗС - 20, ЗАВ - 20 механикалаштырылган ашлык чистарту агрегатлары нигездә сафта. Шулай да хуҗалыкта аларның искеләрен - җирлеләрен дә карап куярга ниятлиләр.

Бер үк вакытта склад хуҗалыгына да «ревизия» ясала. Аларның байтагы иске, ашлык кебек кыйммәтле әйбер сакларлык түгел. Шул ук вакытта аларны төзәтү дә файдасыз. Шуңа да бүген РСУ җитәкчелеге ябык түбәле зур ындыр табагын склад итеп үзгәртеп кору хәстәрен күрмәкче була.

... Басуларда игеннәр шаулый. Биек, куе булып үскәннәр алар быел. Көннән - көн тулыша барган башаклар санаулы көннәр эчендә урак якынлашуын искәртә. Күп тә үтмәс, урман аланлыклары, тау битләрендәге басуга комбайннар да чыгар. Комлы, көлсу туфраклы җирнең, шул җирдә яшәүче халыкның үзен сынар вакытлары җитәр. Сынау дигәннәре - үстерелгән уңышны югалтуларсыз җыйнап кую: бөртеклеләрнең һәр гектарыннан кимендә 30 центнер уңыш җыеп алу.

**Р.ГИНЯЕВА.**

# Төп фондларны кабат исәплисе

Россия Федерациясе хөкүмәтенең 1996 ел 7 декабрендә чыгарган 1442 нче карары нигезендә барлык төр предприятие, оешма һәм учреждениеләрдә 1997 елның 1 гыйнварена булган төп фондларны кабаттан бәяләү уздырыла. Аның максаты - төп фондларның хәзерге бәяләр белән исәпләгәндәге реаль кыйммәтен ачыклау, шулай итеп инвестиция процессларын һәм салым салына торган базаны оптимальләштерүгә алшартлар булдырудан гыйбарәт. Кабаттан бәяләү барышында төп фондларның тулы бәясе, ягъни теге яки бу фондны 1997 елның 1 гыйнварена булган базар бәяләре һәм тарифлары буенча шундый ук яңа объектка алыштыру өчен күпме чыгым тотарга кирәк булса, шул бәядән чыгып исәпләнелә. Чираттагы бу кабаттан бәяләүнең элекке елларда үткәрелгәннәреннән аермалы үзенчәлекләре дә бар.

Беренчедән, кабаттан бәяләү бу юлы ел дәвамында барачак, чөнки элек ул эшне бик кысырык срокларда уздыру үзе дә кыенга килә һәм бу эшнең нәтиҗәсендә дә чагыла иде. Ә инде бу эшне ел дәвамында үткәрү предприятиеләргә аның иң яхшы дип табылган юлын сайларга - я дәүләт статистика комитеты эшләгән индекслар буенча, я турыдан - туры базар бәяләренә күчереп исәпләп һәм аны соңыннан документлар белән раслатып, я булмаса бәя кую эше белән шөгыльләнергә лицензияләре булган бәйсез эксперт - белгечләрне чакыртып үткәрергә мөмкинлек бирәчәк.

Икенчедән, 1997 елның 1 гыйнварена кабат бәяләү нәтиҗәләре 1996 һәм 1997 еллар өчен оешмаларның милегенә салына торган салымны, шулай ук 1997 елда аммортизация чигерүләрен санап чыгарганда исәпкә алынмый. Ул нәтиҗәләр 1997 ел өчен статистик отчет формаларына һәм 1998 елның I кварталы буенча бухгалтерлык учеты - бухгалтерлык балансына гына кертеләчәк.

Өченчедән, бу юлы төзелеп урнаштырылырга тиешле төп фондларны һәм җиһазларны, тәмамланмаган объектларны кабат бәяләү индекслары системасы да камилләштерелде. Аеруча тузган төп фондларга, промышленностның депрессив тармакларына караган объектларга төзәткеч коэфициентлар куллану мөмкинлеге дә каралган. Ул элек, уртачалаштырып алынган индекслар буенча күтәренкерәк бәяләнгән кайбер төр төп фондларның (хисаплау техникасы, автотранспортның кайбер төрләре, тәмамланмаган төзелеш һ.б.) бәясен киметү мөмкинлеген дә күздә тота. Чит илдән валютага алынган объектларны валюта курсының үзгәрүенә карап индекслау да каралган.

Әмма кабат бәяләүнең камилләштерелгән бу системасы да ул эштә моңарчы җыйналган төгәлсезлекләрне үзеннән - үзе генә тулысынча бетерергә мөмкинлек бирер дип ышандырып булмый. Шуңа күрә төп фондларның бәясен турыдан - туры ачыклау алымнары киң кулланылыр, бәяләүчеләр хезмәтенә мөрәҗәгать итәргә дә туры килер дип уйлыйбыз. Әмма соңгысына килгәндә, бу мәсьәләдә бик сак булырга, очраклы кешеләр хезмәтенә мөрәҗәгать итмәскә кирәк. Шуңа күрә дә дәүләт статистика органнарында предприятие бухгалтерларына бу мәсьәләләрдә тиешле консультация хезмәте күрсәтү оештырыла, аерым алганда норматив документлар җыелмасы әзерләнде, бәяләр дәрәҗәсе турында мәгълүмат та бирелә. Моннан тыш, статистика комитеты предприятиеләр белән абонемент мәгълүмат - белешмә хезмәте күрсәтүгә килешүләр төзи. Бәя кую эшчәнлеге белән шөгыльләнергә хокукы булган оешмалар һәм физик затлар белән хезмәттәшлек турында килешүләр төзелә һәм андый очракта соңгылары инде статистика комитетының эксперт оешмасы ролендә чыгыш ясыйлар.

Төп фондларны кабат бәяләү эшенә никадәр җитди каралса, предприятие, оешманың мөлкәте турында шулкадәр реальрәк хәл ачыкланачак. Ә бу гаять мөһим, чөнки төп фондлар предприятиенең салым салына торган мөлкәтенең зур өлешен тәшкил итәләр.

**Ф.САФИУЛЛИНА,**
**район дәүләт статистика бүлеге башлыгы урынбасары.**



# НӘСЕЛЕ ДӘВАМ ИТӘ

Юлия Мизонова Тәрнәс совхозында терлекче. Бу сүз үз эченә сыер савучы хезмәтен дә һәм хәзерге вакытта мәшгуль булган бозаулар карауны да үз эченә ала. Юлия Владимировна озак еллар буе үз хуҗалыгында гына түгел, районда, кайчандыр республикада да танылган, алдынгы сыер савучы булып килде. 80нче елларда аның сыерлары елына 7000шәр мең килограмм сөт биреп хуҗабикәләрен данлыклы иттеләр. Ул гына түгел, хуҗалыкка, районга зур горурлык китерделәр. Мизонова конкурсларда катнашып урыннар яулап килде, заманында ВДНХ тарафыннан көмеш медаль белән дә бүләкләнде. Бу еллар артта калды, әмма Юлия Владимировна тугърылыклы калды, хәзер инде элекке рекордларга үрелмәсә дә, профилакторийда бозаулар үстерүдә үзен сынап карады һәм уңай нәтиҗәләргә иреште. Хикмәт шунда да, зурак физик көч таләп иткән хезмәттә үзен танытa алган Юлиянең бу эшкә дә куллары ятып тора икән бит. Балаларын карагандай, 60лап бозавын тәрбияли, ашату вакытын, җаен, рационын билгеләү - һәммәсенә тиз төшенде, нәтиҗәдә бозаулары көр, саннарга караганда сакланышлары да әйбәт, артымнары да 700-750 граммга җитә. Юлия Мизонованың тырыш хезмәте бу юлы да уңай күрсәткечләрен бирә.

Ана холкындагы эшкә бирелгәнлек, алдынгылык рухы гаиләдә дә хөкем сөрми калмый. Кызы Татьяна әнисе юлын сайлый, шунда ук сыер сава, улы Александр да терлекләр карый. Шулай итеп, данлыклы сыер савучы - терлекченең нәселе дәвам итә.

**Рәсемдә: Ю. Мизонова.**
**Н. КВАШНИНА фотосы.**

## Әдәплелек дәресләре

***Без үз - үзебезне тота беләбезме? Кунакка баргач, уңайсыз хәлдә калмыйбызмы? Бүген сүзебез ул хакта.***

**Ипине** гомуми тәлинкәдән кул белән алалар. Чәнечке белән ипи алу әдәпсезлек санала. Ипине сындырып - сындырып ашарга кирәк.

**Сырны** исә махсус чәнечке белән алып, үз тәлинкәңә салу мәгъкуль.

**Балык** уылдыгын савытыннан пычак очы белән алып, ак ипигә ягып ашыйлар. Уылдыкны ашар алдыннан гына алырга кирәк. Уылдыклы бутербродны кулга тотып ашыйлар.

**Торт, пирогны** гадәттә кисеп китерәләр. Аны махсус прибор белән үз савытыңа салырга һәм чәй кашыгы яки махсус чәнечке белән ашарга кирәк.

**Печеньены** сындырып ашыйлар.

**Конфетны** савыттан ике бармак белән чеметеп алырга кирәк. Кәгазьле конфет булса, аны үз тәлинкәңдә чистарталар.

**Алма һәм грушаны** тәлинкәдә дүрт яки сигез өлешкә бүләләр. Аннан аны кабыгыннан һәм төшләреннән чистарталар.

**Әфлисунны** өстәлгә аркылыга. Бөтен апельсин булса, пычак белән аны буйдан - буйга чәчәк кебек кисеп чыгалар. Аннары гына чистарталар.

**Бананны** сул кул белән алалар һәм чистартырга уңайлы булсын өчен, башын пычак белән кисеп, яртысына кадәр генә чистартып ашыйлар.

Бананны кул белән тотып ашыйлар. Ә менә Англиядә аны башта чистартып бетерәләр һәм чәнечке белән тәлинкәдән алып ашыйлар.

**Ананасны** гадәттә өстәл янында кисәләр. Чөнки аның исе бик тәмле. Ананасны аркылыга юка итеп кисәләр һәм пыяла савытта бирәләр.

Әлбәттә, өстәл артында утырганда теге яки бу әдәп кагыйдәсен онытып җибәрергә дә мөмкин. Шулай булмасын өчен өйдә дә үзеңне гел кунакта утыргандагыдай хис итәргә кирәк. Шул чагында үзеңне кунакта да уңайсыз тоймассың. Гомумән, табынны да һәркөн кунак табыны әзерләгәндәй матур итеп, зәвык белән әзерләсәң, үзеңнең дә күңелең шат, кәефең күтәренке булыр. Балалар өчен дә менә дигән әдәплелек дәресе булыр иде бу.

## Сорагыз - җавап бирәбез

# УЛЫГЫЗ АРМИЯДӘН КАЧСА...

Армиягә алынган егет теге яки бу сәбәпләр аркасында хезмәт итә торган частен калдырып кайткан яки качкан очракта аның ата - аналарына, туганнарына нишләргә? Шул уңайдан берничә киңәш:

1. Һич тә аны яшерергә тырышмаска кирәк. Солдат частеннан никадәр озаграк югалып торса, бу аның өчен шулкадәр начаррак. Ул йә дисциплинар батальонга, йә төрмәгә эләгергә мөмкин. Чөнки яңа Җинаять кодексында моның өчен җаваплылыкка тарта торган статьялар бар (337, 338 статьялар).

2. Икенче көнне үк солдат белән йә хәрби комиссариатка, яки яшәү урыныннан ерак булмаган хәрби прокуратурага барып, гариза язарга кирәк. Бу очракта ул дезертир булып саналмаячак. Гаризаны ике данәдә язу кулайрак, һәм сездә кала торганына да хәрби комиссариатта яки прокуратурада билге куйсыннар.

3. Әгәр солат ни өчен частеннан киткәнен аңлаешлы һәм ышандырырлык итеп сөйли алса, аны хезмәт иткән частена кире кайтармаячаклар һәм җинаять җаваплылыгына тартмаячаклар (Җинаять кодексының 37 һәм 39 нчы статьялары).

Хәрби комиссариатта яки прокуратурада ни өчен качарга мәҗбүр булуы турында рапорт язганда шушы статьяларны урынлы куллану файдалы булачак. Шулай ук качарга мәҗбүр иткән сәбәпләрне һәм фактларны да күрсәтү мәҗбүри.

4. Әгәр дә солдатның тәнендә кыйналудан калган җәрәхәтләр, күгәргән урыннар булса, кичекмәстән врачларга мөрәҗәгать итеп, белешмә алырга кирәк. Алар баш тартса, прокуратурадан юллама алырга кирәк.

5. Солдатны бер частьтән икенчесенә күчерү турындагы документларны ахырына кадәр әзерләп бетергәнне таләп итәргә кирәк. Бу - бары тик хәрби округның штабыннан алынган боерык (предписание) булырга тиеш.

6. Хәрби комиссариатта яки прокуратурада улыгызны дезертирларны аклый торган пунктка җибәрүләрен һәм моның өчен язма рәвештә юллама бирүләрен таләп итегез.

7. Кирәк булса, улыгызга яңадан медицина тикшеренүе үткәрүләрен сорагыз.

8. «Улыгызны армиядән коткарабыз» дигән төрле җәмәгать оешмаларына ышанып, вакытны сузмагыз. 100дән 99 очракта бу файдасыз. Врачлардан сатып алынган ялган белешмәләрнең дә бу очракта булышмавы мөмкин.

9. Бу мәсьәләдә нинди генә оешмага мөрәҗәгать итсәгез дә, мөһер сугылган рәсми кәгазь алырга тырышыгыз.

10. Әгәр сезгә, улыгыз частеннән качты, ләкин тотылды, дип хәбәр итсәләр, тиз арада аның янына барыгыз һәм урында бөтен мәсьәләләрне хәл итәргә тырышыгыз.

**«Московский комсомолец».**

## Памперслар зарарлымы?

***«Хәзер телевидениедән дә, радиолардан да гел памперсларны рекламалап торалар. Алар сәламәтлек өчен зарарлы түгелме соң?***

**Ә.ГАЛИЕВА.**

**Казан».**

Сүз дә юк, памперслар куллану өчен бик уңайлы. Гомумән, хәзер бала үстерү бик «җиңел»: барысы да әзер, ашатырга төрле - төрле ялтыравыклы банкаларда ашамлыгы дисеңме, памперсы, асып йөри торган сумкалармы...

Ләкин яшь әниләр шуны да онытмасын иде, памперслар гел химик материалдан гына эшләнгән. Алар формальдегид, фенол, метонал, хәтта крезол да бүлеп чыгаралар икән. Шуңа да педиатрлар 2 айга кадәрге балаларга, гомумән, памперс кидермәскә, ә 6 айга кадәргеләренә бик кирәк чакта һәм тәүлеккә 6 сәгать дәвамында гына кидерергә киңәш итәләр.

**(«Ватаным Татарстан»нан)**

*Аш - су*

## АЛМАЛЫ КАТЛАМА



Бер стакан җылы сөткә 50 г чүпрә салып күпертегез.Аннары 400 г атланмай яисә маргаринга 2 стакан он кушып умач ясагыз.Шул уманчы угыч аша чыгаргач, чүпрәле сөт белән болгатып камыр куегыз. Барлыкка килгән камырны иң элек сигез тигез өлешкә бүлегез дә, янәдән һәрберсен кабаттан сигезгә бүлеп чыгыгыз.Әлеге камыр кисәкләрен тасмалап җәйгәннән соң, уртасына ваклап туралган шикәрле алма салып рулетсыман төрегез.Катламаның ике баш-башыннан сак кына бармак белән тотып, бер ягын туглаган йомыркага манчып алыгыз. Ул манчылган ягын өскә калдырып майланган табага тезеп чыгыгыз. Аннары һәр катлама өстенә төелгән әчтерхан чикләвеге белән катнаш шикәр комы сибеп мичкә куегыз.

Мондый катлама чәй табынына менә дигән тәмле ризык була ала.

Катлама әчлегe өчен төрле җиләк-җимеш, джем һәм повидло да кулланырга мөмкин.

## Бавыр паштеты

Дүрт телем ак ипи яисә күмәчне ваклап турагыз да, өстенә бер стакан сөт салып йомшартырга куегыз.

Ул арада 500-600 г. бавырны юып, кан тамырларыннан яхшылап чистартыгыз.Шуны бер баш суган белән бергә иттарткычтан чыгарыгыз. Әлеге бавыр боламыгына тоз, борыч, бер йомырка һәм йомшартылган ипи кушыгыз.

Барысын бергә яхшылап болгатканнан соң, майлы табага яисә кечкенә кекс формаларына салып мичтә пешерегез.Пешкән паштетны өлешләп кискәләп, каймак яисә яшелчә салаты белән табынга бирегез.

**Роза МӘСЛӘХОВА**

## ДҮРТЬЮЛЛЫКЛАР

Яман гадәтләрнең берсе -
Сүз йөртү,
Юхаланып кеше күңеленә
Ут төртү.
***
Тормыш
йөген тарткан чакта
Шуны ая,
Дөресме соң барыр юлың,
Кыйблаң кая?
***
Ялган сүзне бер тапкыры
Әйтү җитә,
Ялганчы дигән «дан»ың да
Шуннан китә.
***
Берәүнең дә бу дөньяда
Юк калу әмәлләре,
Җаны белән бергә китә
Үлчәнер гамәлләре.
***
Кеше үзен бөегрәк
Тойган саен,
Түбәнлеккә төшә бара
Торган саен.
***
Әй оста уйныйсың үзең,
Тормыш, диеп, театр,
«Артист» икәнең беләбез -
«Театрың» куеп тор.
***
Кайчак авыр сүзләр әйтү
Җиңел, уен,
Түзем булып дәшми калу
Бигрәк кыен...
***
Кеше күңеленә әгәр дә
Салсаң яра,
Үзеңне
шул кеше урынына
Куеп кара.
***
Беләм, дустым, уең изге,
Йөзеңә чыккан - күзең көзге.
***
Үзеңне
зур куеп масайма бик,
Кыланышың ясалма бит,
«Зур»лыгыңны кеше белә,
Моны әйтми ул үзеңә
Әчтән генә әмма көлә.
***
Басканчыга кадәр
Кабер ташы,
Ниләр генә күрми
Адәм башы...

## Сез беләсезме?



Россиядә тамыр җибәргән төрле сектaлар җәтмәсендә 3-5 миллион кеше бәргәләнә. Аларның күпчелеге яшьләр.

Илдә чама белән 130 миллион кеше булсын ди. Шуларның 38 миллионы пенсионерлар.Миллионнан артык кеше наркоман һәм эчкече.Боларга төрле сектaлар кулына эләккән кешеләрне дә кушсаң, бу беткән илне кем генә күтәрер соң?

***

Май аенда Руссия Дәүләт Думасы кабул иткән минималь хезмәт хакы 83.490 сум. Бу акча Мәскәүдә метрода йөрергә дә җитми.

1990 елдан бирле Россиядә бәяләр- 6,5, ә минималь хезмәт хакы 1,2 мең тапкыр гына үсте. Статистика мәгълүматларына караганда, Россиядә миллионнан артык кеше минималь хезмәт хакына якын (аена 100 мең сум чамасы) акчага гомер сөрә.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Киекле авылында яшәүче әтиебез **Нәфыйкъ Нуретдин улы Насретдиновка** 13 июльдә 60 яшь тула.

Кадерле әти! Сине олы юбилееың белән тәбрик итәбез.



Озын гомер бирсен ходай дибез,
Кояш сиңа бирсен яктылык.
Балаларың гына түгел, оныкларың
Китерсеннәр иде яхшылык.
Яшәү маягы син безнең өчен,
Кешелегең белән үрнәк син.
Мең-мең рәхмәт тәрбияңә синең
Безнең өчен һәрчак кирәк син.

**Тормыш иптәшең, балаларың, килен-кияүләрең, оныкларың.**

## Белдерүләр

### Сатабыз

**УАЗ - 469.** Тел.: 2 - 19 - 56.

***

**«ИЖ - Юпитер 4К», кыйммәт түгел, «Урал» (3,5 мең км. юл үткән)**. Адрес: Советская ур., 77 - 10 (16.00 сәг.тән соң).

***

**Пушкинода фундаменты салынган участок (бәясе - киметелгән), фундамент блоклары, кызыл кирпеч.** Тел.: 2 - 11 - 34.

***

**1994 елгы ВАЗ - 2106.** Тел.: 5 - 21 - 19 (16.00 сәг.тән соң).

***

**7 х 10 метрлы бура.** Адрес: Лермонтов ур., 3.

***

**Югары Норлатта шәхси йорт.** Адрес: К.Маркс проспекты, 2 - 8.

***

**Шифер, керамзит - бетон блоклар, кыйммәт түгел.** Тел.: 5 - 11 - 22.

***

**60 лет Октября урамында ашыгыч төстә 2 бүлмәле фатир**. Пионерская ур., 2а - 6 адресына мөрәҗәгать итәргә.

***

**Ашыгыч төстә 1984 елгы ВАЗ - 2105.** Тел.: 5 - 20 - 03.

***

**ВАЗ - 21011, кыйммәт түгел**. Советская ур., 114 - 6.

***

**Кулланылышта булган йокы гарнитурын ашыгыч рәвештә.** Советская ур., 187 - 14.

***

**Йорт**. Комсомольская ур., 31, тел.: 2 - 16 - 01.

***

**1996 елгы ВАЗ - 2121 «Нива»**.
Тел.: 2 - 17 - 19, 5 - 24 - 50, (18.00 сәг.тән соң).

***

**Ретранслятор районында фундаменты белән гараж урыны.** Тел.: 5 - 17 - 93.

***

**1983 елгы ВАЗ - 21053**. Тел.: 5 - 26 - 99.

***

**1 бүлмәле фатир (гомуми мәйданы 35 кв.м.), канализациясез.** Красноармейская ур., 63 - 7.

***

**«Мерседес - 200», ГАЗ - 66, ГАЗ - 53, шәһәр уртасында участок.** Победа ур., 11 йортка мөрәҗәгать итәргә.

### Алмаштырабыз

**Норлаттагы ике бүлмәле фатирны - Тольяттидагы шундыйга ук**. К.Маркс проспекты, 9 - 25.

***

**5 каттагы 3 бүлмәле фатирны - 2 һәм 1 бүлмәлеләргә.** Тел.: 5 - 23 - 19.

***

**«53 нче СМУ» чикләнгән җаваплылыктагы җәмгыятенә даими эшкә автокранчылар, С,Д,Е категорияле шоферлар, Т - 130, К - 701 тракторларына тракторчылар, токарьлар, торба салу машинасына шоферлар, электр һәм газ белән эретеп - ябыштыручылар, прораб һәм мастерлар кирәк.**

Белешмәләр өчен телефоннар: 5 - 29 - 34, 2 - 26 - 86.

**Сатуда киндер сүс бар, төргәге 330 мең сум.**

### Төрлесеннән

**4 нче мәктәп тарафыннан Газизова Гүзәлия Минвәгыйзовна исеменә бирелгән А 1292326 номерлы аттестатны, югалу сәбәпле, гамәлдән чыккан дип санарга.**

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2306 данә. Заказ N 7197